**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Алькеевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального**
**района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы Әлкэй авыл**
**җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

Пер. Советская, 44а, село Алькеево
Азнакаевского муниципального района,
423309
Тел. (факс) (85592)37-4-23
Alk.Azn@tatar.ru

Совет тыкрыгы , 44а, Әлкэй авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
423309
Тел. (факс) (85592)37-4-23
Alk.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» март 2024 ел № 2

«2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкэй авыл җирлегенең Әлкэй авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2023 елның №1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкэй авыл җирлегенең Кызыл Сукачы авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында»гы, 2023 елның 02ноябрендэге №2 карарлары буенча «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкэй авыл җирлегенең Әлкэй авылында гражданнарның җыенын билгеләү хакында»

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «2024 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында» 2023 елның 1532 номерлы карары, Әлкэй авыл җирлеге Әлкэй авылының 22 ст. Уставы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әлкэй авыл җирлеге муниципаль берәмлек Башлыгы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. «2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкэй авыл җирлегенең Әлкэй авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2023 елның 02 ноябрендэге №1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкэй авыл җирлегенең Әлкэй авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында»гы 2023 елның №2 карарлары буенча 2024 елның 18 мартында 14 сәгать 00 минутта гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкэй авыл җирлегенең Әлкэй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 02.11.2023 ел № 1, «Әлкэй авылында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында» 02.11.2023 ел № 2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1)су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (эчә торган су линияләрендә, су ала торган колонкаларда өзеклек булганда аларны ремонтлау)

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;(карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен туләү, чит оешмаларнын юлларны кардан чистарту хезмәтләре, Совет урамын төзекләндерү);

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (механикалаштырылган чаптыру хезмәтләре өчен туләү,шартнамә буенча эшләр өчен түләү, Әлкэй авылы территориясендә яшелләндерү чаралары, җирлектә яшәүчеләэр өчен массакулэм ял итү өчен шартлар тудыру, халык күплэзп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру (Әлкэй авылында парк төзекләндерү))

алу, аны урнаштыру);

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында (http:// aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы ______________ С.З.Зиннурова